РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» сентябрь 2023г. г. Альметьевск № 118

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенең 31 бүлеге, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 29 статьясы нигезендә

Әлмәт шәһәре Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 2 октябрендәге 141 номерлы, 2014 елның 19 ноябрендәге 151 номерлы, 2015 елның 6 маендагы 179, 2015 елның 20 ноябрендәге 13, 2016 елның 8 ноябрендәге 49 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 122 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 126, 2019 елның 28 августындагы 166 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 189 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 206 номерлы, 2021 елның 17 июнендәге 37 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 49 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 68 номерлы каралары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

«- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкка мөлкәти ярдәм инфраструктурасы субъектларын аккредитацияләү турында» 2014 елның 27 августындагы 616 номерлы карары нигезендә аккредитацияләнгән кече һәм урта эшкуарлыкка мелкәти ярдәм инфраструктурасы субъектлары реестрына кертелгән сәнәгать (индустриаль, агросәнәгать) паркы һәм сәнәгать технопаркы (алга таба - сәнәгать паркы) биләгән җир кишәрлекләре, 1 елга»;

1.2. 3 пунктның унберенче һәм уникенче абзацларын тиешенчә уникенче һәм унөченче абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 01 январеннан барлыкка килгән хокук менәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов